Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Кощаково авыл җирлеге

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Кощаково авыл җирлеге Кощаково авылының Панков, Төзүчеләр, Яшьләр, Җиңүнең 50 еллыгы, Чокыр арты, Яшел, Елга арты урамнары гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**КАРАР**

23 октябрь, 2022 ел

№ 1

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Кощаково авыл җирлеге Кощаково авылының Панков, Төзүчеләр, Яшьләр, Җиңүнең 50 еллыгы, Чокыр арты, Яшел, Елга арты урамнарында яшәүчеләрнең 2022 елның 23 октябрендәге гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә авыл җирлегендә яшәүчеләр белән очрашу беркетмәсе нигезендә:

- җыенны уздыру өчен билгеләнгән территориядә яшәүче һәм халык җыенында катнашырга хокуклы гражданнар саны 331 (өч йөз утыз бер).
- халык җыены эшендә катнашкан гражданнар саны 167 (йөз алтмыш җиде).
- гражданнар җыенына кертелгән мәсьәләгә «**РИЗА**» өчен гомуми сан 167 (йөз алтмыш җиде).
- гражданнар җыенына кертелгән мәсьәләгә «**КАРШЫ**» өчен гомуми сан 0 (ноль).

Югарыда бәян ителгәннәрдән чыгып түбәндәге карар кабул ителде:

1. «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25 статьясындагы 6 өлеше нигезендә түбәндәге сорау буенча «Сез 2023 елда Кощаково авыл җирлеге Кощаково авылының Панков, Төзүчеләр, Яшьләр, Чокыр арты, Яшел, Елга арты урамнарында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган һәр кешедән, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен куллану белән килешәсезме?:

- гомуми файдаланудагы урыннарны төзекләндерү

**кабул ителгән дип санарга.**

2. Әлеге карарны «Вперёд» («Алга») газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) һәм Кощаково авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында да бастырып чыгарырга (халыкка игълан итәргә).

Питрәч муниципаль районы
Кощаково авыл җирлеге башлыгы

З.Н. Саттарова